**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ШИЛНӘБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

КАРАР

18 октябрь 2019 ел Шилнәбаш авылы № 34

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Шилнәбаш авыл җирлегендә үзара салым
акчаларын кертү һәм алардан файдалану
мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Шилнәбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР:

1. 2019 елның 30 октябренә Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Тогаево авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда яшәү урыны буенча Шилнәбаш авыл җирлеге Тогаево авылында территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:
- юл ремонты;

"ӘЙЕ" "ЮК".

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адресы буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Тогаево авылы, Үзәк урам , 15 йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Баш
Шилнәбаш авыл җирлеге башлыгы О. А. Гончарова